**РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН**
ЧЕРЕМШАНСКИЙ
МУНИЦИПАЛЬНЫЙ РАЙОН
**СОВЕТ ТУЙМЕТКИНСКОГО**
**СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ**

ул.Школьная ,дом 4, с.Туйметкино, 423108

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
ЧИРМЕШӘН МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
**ТУЙМӘТ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ**
**СОВЕТЫ**

Мәктәп урамы, 4 нче йорт, Туймәт авылы, 423108

тел./факс email: 8-(84396) 3-72-90. Tuy.Cmn.2@tatar.ru

**№ 19** **29 март 2021 ел**

Татарстан Республикасы
Чирмешән муниципаль районы
Туймәт авыл җирлеге Советы
КАРАРЫ

**Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Туймәт авыл җирлеге Советының 2019 елның 19 сентябрендәге 129 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Туймәт авыл җирлеге составына керүче торак пунктларда гражданнар җыенын әзерләү һәм үткәрү тәртибе турындагы нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1 статьясын, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясын гамәлгә ашыру максатларында, Чирмешән муниципаль районының «Туймәт авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставы нигезендә Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Туймәт авыл җирлеге Советы **КАРАР ИТТЕ:**

1. Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Туймәт авыл җирлеге Советының 2019 елның 19 сентябрендәге 129 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Туймәт авыл җирлеге составына керүче торак пунктларда гражданнар җыенын әзерләү һәм үткәрү тәртибе турындагы нигезләмәгә үзгәрешләр кертергә:

1) 1.7 пунктта өченче, дүртенче, бишенче абзацларны төшереп калдырырга;

2) 2.10 пунктта «Гражданнар җыены турындагы нигезләмә нигезендә» сүзләрен төшереп калдырырга;

3) 3.7 пунктта «(вариант буларак: форма Гражданнар җыенын әзерләү һәм үткәрү тәртибе турында нигезләмә белән билгеләнә)» сүзләрен төшереп калдырырга;

4) 3.13 пунктында «(вариант буларак: форма Гражданнар җыенын әзерләү һәм үткәрү тәртибе турында нигезләмә белән билгеләнә)» сүзләрен төшереп калдырырга.

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (PRAVOTATARSTAN.RU) һәм Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы сайтында Интернет мәгълүмати-телекоммуникация челтәрендә урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуда җаваплылыкны үз өстемә алам.

ТР Чирмешән МР
Туймәт авыл җирлеге
башлыгы, Совет рәисе А.Б. Кәримов